Март – май, 2022

# Гимназия сулышы №3

25 нче гимназия укучылары газетасы

## Хәтер маршы 2022

***Гимназиядә 257нче укчы дивизиянең 80 нче чаңгы батальоны сугышчыларының батырлыгының 80 еллыгы уңаеннан агитбригада чыгышы күрсәтелде .Чарада 8 а,б,г сыйныф укучылары, «Яшь армиячеләр» катнашты.***



Бу тарих 2002 елда, Түбән Камадан «Эзләнү (Поиск)» отряды 257 укчы дивизиясе, ягъни 80нче аерым, татар чаңгы батальоны частьләрендә сугышкан якташларның язмышларын билгеләүгә керешкәч башлана.

2020 елның 31 гыйварында шәһәр зиратында туганнар каберлеге ачылды. Анда Бөек Ватан сугышы чорында Псков өлкәсендә барган сугышларда һәлак булган 19 солдат җәсәде алып кайтып җирләнде.
Билгеле булганча, 1941 елның декабрендә Липенка авылы (Псков өлкәсе) янындагы көрәшләрдә 100 гә якын кеше батырларча һәлак булган. Аларның иң өлкәненә – 36 яшь, күпләренә 18 яшь була.Татар батальоны фашист илбасарлары белән соңгы сулышка кадәр көрәшә. Көрәш бер тәүлек дәвам итә, исән калучыларга алга таба хәрәкәт итәргә боерык бирелә, һәлак булган Татарстан, Башкортостан һәм Себер солдатларын авыл халкы җирли. Батырларча сугышып, яу кырында һәлак булган каһарманнар арасында ике якташыбыз бар. Алар – Мөҗип Юныс улы Юнысов һәм Нурулла Шәрифулла улы Шәрифуллин Бөек Ватан сугышына Шәңгәлче авылыннан киткәннәр. Ватан өчен башын салган солдатларның исемнәре 75 елдан сон шулай мәңгеләштерелде.





**Ислам дөньясында олы вакыйга**




«2022 елда Россиядә Ислам кабул ителүнең 1100 еллыгы билгеләп үтеләчәк. Бәйрәмнең төп чаралары Татарстанда узачак, » - дип башлады сүзен сыйныф сәгатендә гимназиянең тарих укытучысы Аслямова Гүзәл Зәһретдин кызы. Ул 922 елда Идел буенда Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул ителүнең Россия цивилизациясен Көнбатыш һәм Көнчыгышка танытуда зур роль уйнаганын билгеләп әйтте. Болгар дәүләтендә Ислам халыкны берләштерергә , мәҗүсилектән ( язычество) арындырырга булышкан. Укучылар кызыклы видеоролик караганнан соң викторина сорауларына җавап бирделәр һәм фикер алыштылар.
Баранкова Дана



**Туган тел ул -бер генә!**

Рус, татар, чуваш, әрмән, үзбәк, башкорт, немец, казах халыкларының милли киемнәрен кигән укучылар сәхнәдә төрле телләрдә шигырьләр сөйләде, җырлар җырлады, милли биюләр күрсәтте. «Туган тел» бәйрәме укучыларны, эти-әниләрне, укытучыларны шул рәвешле бергә җыйды. Туган тел ул - һәр халыкның үзенә бик кадерле һәм якын, ата-бабадан калган мирас.



«Бүгенге матур концерт төрле милләт балалары укыган гимназия укучыларын берләштерәдә бик уңышлы булды, -диде Кама таңнары әдәби берләшмәсеннән килгән язучы Вәсимә Сәлахова.
Хуҗҗәтов Гадел



## Тырышлык җиңүгә илтә

*Техник модельләштерү-кеше тормышында техник белгечлекләрне үзләштерүгә юл, техника һәм спортның техник төрләре белән кызыксынуны үстерү, балаларда конструкторлык фикерен үстерү һәм барлык эшләрдә хезмәт сөючәнлекне үстерү ул.*
"Фанерадан могҗиза ясау" түгәрәгендә укучылар модельләштерү генә түгел, ә «зур» техника белән дә бәйле теоретик белемнәргә һәм практик эшчәнлеккә өйрәнәләр



«Балалар модель булдырырга өйрәнәләр , башлап уй-фикерләре кадәр техник гамәлгә ашыру проектын тормышка, ә киләчәктә модель «җитди» эшләнмәгә әверелергә мөмкин. Моның өчен инструментлар белән дөрес эшләү, алар белән куркынычсызлык техникасы кагыйдәләрен белү кирәк,»- ди түгәрәк җитәкчесе гимназиянең технология укытучысы Анатолий Иванович Попов.
8 а сыйныфы укучысы Семёнов Тимофей әлеге түгәрәккә инде өч ел дәвамында йөреп шактый тәҗрибә туплаган бик сәләтле егет. Быел ул «Технология» фәне буенча олимпиадада муниципаль этапта һәм Республика буенча беренче урында яки җиңүче. Афәрин,Тимофей! Исламова Карина

## Гаилә әлифбасы

Түбән Кама ЗАГС ында мәктәп укучылары өчен “Гаилә нигезләре әлифбасы» проекты буенча кызыклы чара булды. Анда гимназиянең 5 В сыйныфы укучылары катнашты.
Укучылар күңелле башваткыч чиштеләр, ЗАГС тарихы турында күп мәгълүмат белделәр. Качаева Диана






## Һөнәрләр күп, кайсын сайларга?



Март- апрель айларында 8 сыйныф укучылары Түбән Каманың һөнәри белем бирү колледжларына барып төрле белгечлекләр буенча мастер-класслар карадылар. «Түбән Каманың һөнәр дөньясы” проекты мәктәп укучыларына үзе теләгән һөнәр белән якыннан танышырга мөмкинлек бирә.



## Шигырь бәйрәме

Жыры барның җирдә даны булыр,
Бәйрәмнәре булыр мәңгегә.
Без — бәхетле, без — шагыйрьле халык
Без — Тукайлы халык мәңгегә!

Г.**Тукай** - татар милләтенең бөек шагыйре. Аның әсәрләре белән һәр бала кече яшьтән таныша, җырларын көйли. Гимназия укучылары шагыйрьнең шигырьләрен яратып укыйлар, хәтердән сөйлиләр. Әкият геройларын рәсемгә төшерәләр. Бөек шагыйрьнең туган көнендә гимназиядә шигъри бәйге үткәрелде. Укучылар Тукайның шигырьләрен тырышып өйрәнгәннәр һәм зур осталык белән сөйләделәр. 1 урын Баязитов Эмильгә (4 сыйныф)һәм Никонова Ангелинага (9 сыйныф). 2 урын Афанасьева Викториягә , 3 урын Гайфутдинов Инсафка (6 сыйныф) бирелде. Соңыннан бергәләп фотога төштеләр. Алексеева Лариса






25 майда унберенчеләр өчен гимназиядә соңгы кыңгырау чыңлады! 11нче Аның 30 чыгарылыш сыйныф укучысы Бердәм Дәүләт имтиханын тапшырып кулларына аттестат алды. Олы тормыш юын узганда хыялларыгызның чынга ашуын телибез, сезгә укучылар!



**Проект җитәкчесе Шарапова Н.Н.**